Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы
торак пунктында үткән гражданнар җыены

# КАРАРЫ

2022 елның 25 ноябре № 2

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге составына керүче Олы Солтан авылы торак пунктында үткән гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегендә тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (уку йортларына көндезге бүлекләргә йөреп укучы студентлардан һәм 1 группа инвалидлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
   - авыл җирлегенә керүче торак пунктлар чикләренә кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү;
   - кышкы чорда авыл җирлегенә керүче торак пунктлардагы юлларны карап торуга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфеев урамы, 12 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Р.Р.Сөнгатуллин

Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы : Р.Р.Сөнгатуллин

СОВЕТ БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1634000725 ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ